





### 12 НЧЕ ГИМНАЗИЯ ГИМНЫ

**Нәҗибә Сафина сүзләре,**
**Сәйдә Вәлиди көе.**

1. Язмышыма язлар булып керде.
Мәгърифәтле бина - гимназия!
Ул бүген дә киләчәкне саклар, саклар
Гали җанлы балаларны җыя.

***Кушымта:***

Зирәк акыл татар теле белән
Сөйләр кызларны ул бүген җыя.
Татар язмышына яз китерер, китерер
Айлы затлы уникенче гимназия!

2. Җылы эзләп сиңа сыеначак
Затлы татар халкы йолалары.
Олуг хатын-кызның җаны булып,
Челтер-челтер ага елгалары.

***Кушымта.***

3. Бөреләре язның ачылачак,
Янраячак әле моңнар.
Идел-йортка үзе ана булыр
Монда укый торган кыз балалар!

***Кушымта.***

“КЫЗЛАР ИЛЕ” ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ

Безнең адрес: 420034, Татарстан, Казан ш., Декабристлар ур., 89А.
Тел/факс: (843) 562-25-43
E-mail: kzlar_ile@mail.ru

**Баш мөхәррир:** Рәмилә ГАЗИЗУЛЛИНА
**Шеф-мөхәррир:** Илһамия Абделхәй кызы ТЕМИРКӘЕВА

**Редколлегия:** Гимназиянең “Нур” балалар оешмасы әгъзалары
Р.Т. ХУҖИНА
Г.З. НАСЫЙБУЛЛИНА

*ЗЫЯЛЫ КЫЗ — ИЛ КҮРКЕ!*

# КЫЗЛАР ИЛЕ

Ф.Г. Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче
12 нче гимназия укучылары газетасы
2012 елның февраль аеннан бирле чыга

6+

№3 (4) Декабрь, 2013 ел

## Юбилей санында:

- ***Безнең кызлар — милләтебез киләчәге.*** *3 бит.*
- ***Без — сезнекеләр, Туфан ага!*** *4-5 битләр.*
- ***Хәтерлим мин әле бүгенгедәй...*** *6-13 битләр.*
- ***Фатиха Аитова истәлекләре.*** *14 бит.*
- ***Онытылмас очрашу.*** *15 бит.*
- ***12 нче гимназия гимны.*** *16 бит.*



*ГИМНАЗИЯМ!*
*Сиңа бүген - 20 яшь!*
*Кызлар кебек чагың...*
*Дусларың белән каршыла*
*Яшьлегең таңнарын!*
*Синең укучыларың.*

# БЕЗНЕҢ КЫЗЛАР – МИЛЛӘТЕБЕЗ КИЛӘЧӘГЕ



Менә без дә үсеп життек... 12 нче кызлар гимназиясенә — 20 ел! Бүген без ике дистә елда булган иң күңелле мизгелләрне барлыйбыз...

1993 нче елның сентябре. Хөкүмәт карары белән, Казан шәһәре Вахитов районындагы 17 нче балалар бакчасы кызлар мәктәбенә әверелде. Ун бала... Булыр-булмас бер класс. Әмма нинди: ул чагында республикада татар телендә белем бирүче бердәнбер кызлар гимназиясе!

Безнең гимназия "Ак калфак" Бөтендөнья татар хатын-кызлары берләшмәсенең ул чагындагы җитәкчесе Роза ханым Туфитуллова идеясе белән оешты. Иң сөендергәне: аның фатихасы белән башланган эш бүген дә дәвам итә. Дөрес, без аны бик зур авырлык белән ачтык. Мәктәп Казанның тарихи үзәгендә – Иске татар бистәсендәге сәүдәгәр Галиев йортында урнашкан иде. Ярымҗимерек бина, шартлар юк. Яңа уку бинасы булдыру ниятеннән пикетларга да чыгарга туры килде.

Бәхетебезгә, Туфан ага Миңнуллин тырышлыгы белән, 2011 нче елда гимназиябез заманның бөтен шартларына туры китереп төзелгән яңа бинага күчте. Туфан абыйның хәер – фатихасы белән ачылган гимназиядә кызларыбыз бик теләп, горурланып укый. 10 ел дәвамында Туфан абый гимназия укучылары белән очрашып, аралашып яшәде. Аларда булачак милләт аналарын күрде. Без аңарга мәңге рәхмәтлебез!

Бусагада – яңа заман, яңа өметләр, яңа казанышлар... Гимназиябез дә заман белән бергә атлый. Үтелгән 20 елда 12 нче кызлар гимназиясен 212 укучы тәмамлады, шуларның 40ы алтын һәм көмеш медальләргә лаек булды. Бүген бирелә 24 укытучы хезмәт куя, 310 укучы белем ала. Гимназиябез – төрле милләт балаларының уртак белем йортына әверелде. Нинди генә үрләр яуламый гимназиябезнең чыгарылыш укучылары! Алар арасында айкидо буенча Европа чемпионнары, инглиз теле белгечләре, күренекле җыр-бию осталары да бар. Без укучыларыбыз белән горурланабыз!

Бәйрәмең белән, КЫЗЛАР ИЛЕ!

Гимназиябез үсешенә өлеш керткән һәр кешегә чиксез рәхмәтләремне юллыйм. Бергә һәм бердәм булыйк!

**Илһамия Абделхәй кызы ТЕМИРКӘЕВА,**
**гимназия директоры.**





# "Балкып һәм янып яшәгез, кызлар!"




"Гимназия – белем учагы..." дип җырлана җырларда. Белем алу белән берррәттән, бездә төрле кызыклы кичәләр, очрашулар булып тора. Бүген дә татар теле һәм әдәбияты кабинетында бик тә шаулы: сигезенче һәм унынчы сыйныф укучылары Руфина Фәттаховны кунакка көтәләр. Бүген Нурихан Фәттахка багышланган истәлек кичәсе.

Кызларыбыз аз гына дулкынлана, аларны аңлап та була: берничә минуттан бу кабинетка татар халкының фидакарь улларының берсе булган Нурихан аганың хатыны Руфина ханым керер. Менә ишек ачыла. Укучылар елмаеп торып басалар да, Руфина ханымны сәламлиләр. Ул да безгә елмаеп карый. Без бу мөлаем ханымның җылы карашын тоеп алдык. Уңайсызлану тойгылары юкка чыкты.

Кичә "Кызганмый үзеңне балкып ян һәм яндыр, гасырлар күгендә ялкынлы эз калдыр" дигән сүзләр белән башланды. Башта укытучыбыз Рузилә Тәлгатовна безгә Нурихан ага һәм Руфина апа турында сөйләп китте. Руфина апаның үзенең дә оста язучылардан калышмавын, "Татарстан яшьләре" газетасында басыла торган мәкаләләрен көтеп алганын, укучыларны кызыксындыра торган темалар кузгатуын әйтеп үтте, язучының китапларын күрсәтте. Аннары инде кызлар, сүз алып, Разил Вәлиевнең Нурихан агага багышланган шигырен сөйләделәр. Унынчыларның да, сигезенчеләрнең дә әйтер-сөйләр сүзләре бар иде. Кемнәрдер легендар шәхеснең биографиясеннән кызыклы вакыйгаларны искә төшерде, кемнәрдер аның дәреслектә булмаган хикәя-повестьләреннән алынган тәэсирләр белән уртаклашты. Сигезенчеләрдән Эльвина, Ландыш, Әдилә "Итил суы ака торур"дагы үзләренә ошаган образларга тукталдылар. Юля "Итил суы..."ның сәхнәгә куелу тарихы турында сөйләде. Кызларыбыздан соң сүзне Руфина апа дәвам итте, сорауларга җавап бирде һәм иң актив катнашкан укучыларга үзенең бүләген - Нурихан абыйга багышланган истәлекләр китабын бүләк итте. "Сез булсагыз, яшибез, балалар! Туган телнең дәвамчылары – сез! Балкып һәм янып яшәгез!" – диде ул.

Бу кичә миңа бик ошады. "Мең тапкыр ишеткәнче, бер тапкыр күрүең яхшырак" дигән мәкальдәге кебек, күзгә-күз карап сөйләшкәндәге мәгълүматлар яхшырак истә кала. Нурихан абыйның тормышы заяга узмаган, аның милләтпәрвәрлеге хатынында, балаларында, укучыларында дәвам итә. Күңелне тырнап торган бер нәрсәне дә әйтеп китим инде: туган телебездә аралашу осталыгы җитеп бетми икән әле үзебезгә. Руфина ханымга бик күп сораулар бирәсе килә – дөрес әйтмәм дигән курку тоткарлап тора.

Онытылмас очрашу укучыларның күңелендә мәңге сакланыр. Рәхмәт Сезгә, Руфина ханым!

**Камилә ГАРӘФЕТДИНОВА,**
**10 нчы сыйныф укучысы.**

***Әлеге сәхифәдә без сезне Казанда татар кызлары өчен беренче гимназия оештырган Фатиха ханым Аитова хатирәләре белән таныштырып барырбыз. Бу истәлекләрне укытучы Зәкия Рәсулева Фатиха Аитова гимназиясендә мөгаллимә булып эшләгән Гөлсем Сабитова сөйләгәннәрдән язып алган. Тарихи язманы без ТР Милли китапханәсендә саклана торган 1979 елгы “Сөембикә” журналыннан эзләп таптык.***

# Беренче карлыгачлар



*(Дәвамы. Башы газетаның октябрь санында.)*

Ә бер мәртәбә һич көтелмәгән хәл була. Фатиха апа, укытучы кызларының барысын да пардан киендереп, рус театрына спектакль карарга алып бара. «Әйдәгез, кызлар, тормыштан төшеп калмагыз, дөнья күрерсез», ди.

Үз мохитләреннән аерылып, рус культурасы белән очрашу бу яшь йөрәкләргә әйтеп бетергесез кызыклы була һәм гомерлек эз калдыра. Фатих Әмирхан белән очрашу да кызлар өчен эзсез калмый.

Дин басымы астында изелеп, шуңа буйсынып яшәгән бай хатыннары өчен Фатиханың барлык эшләре гаҗәеп тиешсез булып күренә. Бу надан, кара бай хатыннары Аитованың дәрәҗәсен төшерү өчен нинди генә гайбәтләр таратмыйлар. Аның бөтен эшләренә аяк чалырга, аны хур итәргә тырышалар. Аитова мәктәбе укучы-укытучылары урамнан үткәндә, кара динче сәүдәгәрләр, кәфер почмагы әһелләре мыскыллы сүзләр кычкырып калалар.

Шуңа карамастан, укучыларның саны артканнан-арта, мәктәпнең дәрәҗәсе күтәрелә. Фатиха апа бай кызларын гына түгел, ә күп кенә ярлы кешеләрнең дә кызларын укытырга тарта. Авыр тормышлы балалардан уку хакы алынмый. Читтән килгән, торыр урыны булмаганнарына мәктәп янында торак йорт — пансион булдырыла.

Укучылар күбәя, ләкин аларның өс-башлары бик төрле, бик чуар була: кайсы бай киенгән, кайсы бик фәкыйрь. Фатиха апа укучыларның барысына да бердәй форма кию тәртибе кертмәкче була. Ләкин бу хәбәр ишетелү белән бай хатыннары арасында шау-шу куба. Фатиха безнең кызларыбызга марҗа киемнәре киертмәкче була икән, кызларыбызны приют балалары шикелле итмәкче икән, дип ду киләләр. Фатиха апа моның да җаен таба. Гает бәйрәме көнне (ә ул вакытларда дини бәйрәмнәрне зурлап үткәрү мәҗбүри була) Фатиха үзенең өенә кунакка мөгаллимәләре җитәкчелегендә класслап-класслап укучы балаларны чакыра. Аналар да чакырыла...

*(Дәвамы бар.)*

**Зәкия РӘСУЛЕВА.**

**“Сөембикә” журналы, 1979 ел.**

**Рәсемдә: Аитовлар гаиләсе.**



# Гамьле дөнья




Әле кайчан гына, шау-гөр килеп, гимназиябезнең 15 еллык юбилеен уздырып йөргән идек. Тар кысан бинабызда репетиция ясар өчен урын таба алмагач, Балалар иҗат үзәгенә бөтен гимназиябез белән йөргәннәребез күбегезнең хәтерендәдер әле. Шушы еллар дәвамында мөгаллимнәребез, нинди генә шартларда эшләсәләр дә, халкыбыз өчен һәрьяктан камил үсешкә ия булган эшлекле, зыялы, затлы милләт аналарын тәрбияләүне үзләренә максат итеп куйдылар.

Сизелми генә бер-бер артлы уку еллары узып та киткән. Уйлап карасаң, уку йортының 20 еллык юбилее ул, бер яктан, бик зур мәгънәгә ия булган вакыт аралыгы. Аны тантаналы итеп үткәрү – мәктәп тормышында бик зур вакыйга. Икенче яктан , юбилей ул гади саннар һәм дата гына түгел. Ул гимназиягә кагылышы булган һәрбер кеше һәм вакыйгалар җыелмасы тарихы да. Юбилей ул - гимназиянең беренче угагын кабызучы укытучы-ветераннар, бүгенге көндә армый-талмый тырышып белем бирүче яңа буын укытучылары да. Юбилей ул - гимназия эчендә тәртип тотучы, уңайлыклар тудыручы хөрмәтле хезмәткәрләребез дә. Юбилей ул - үз эшенә җаны-тәне белән бирелгән гимназия директоры Темиркаева Илһамия Абделхәй кызы да. Укучылардан башка нинди мәктәп булсын ди инде! Әлбәттә, юбилей ул - гимназия горурлыгы - чыгарылыш укучы кызлары һәм бүгенге көндә тырышып белем алучы безнең тәрбияле, инсафлы кызларыбыз да. Без, барыбыз бергә, гимназия тормышының гаҗәеп матур мозаикасын тәшкил итәбез.

Елларга иминлек, барчабызга саулык-сәламәтлек, милләтебезгә бердәмлек һәм сабырлык телим. Шушы затлы бай бинада сөекле халкыбызның лаеклы алмашин тәрбияләргә һәм гимназиябезнең күп юбилейларын үткәрергә насыйп булсын иде дигән теләктә калам.

**Гөлнур Зәкәрия кызы**

**НАСЫЙБУЛЛИНА,**

**татар теле һәм әдәбияты укытучысы.**

# С юбилеем, родная гимназия!

...Так получилось, что мне пришлось учиться в разных школах, но ни одна не приняла меня так, как гимназия №12. Я очень благодарна тому, чему она меня научила: воспитанности, культурности, доброте, порядочности. Я благодарна тому, что училась у достойных учителей и приобрела прочные знания, а также нашла настоящих друзей, с которыми общаюсь и по сей день.

Хоть я и не смогла проучиться в нашей новой гимназии, но в моих воспоминаниях навсегда останется та маленькая школа, в которой я до сих пор помню абсолютно все: классы, столовую, коридоры, двор, раздевалку... Несмотря на маленькую площадь, я совершенно не чувствовала себя как-то скованно, некомфортно, наоборот, все казалось очень уютным. И хотелось бы пожелать гимназии и её коллективу долгих лет деятельности, процветания, успехов, хороших учениц. А последним желаю беречь гимназию и наших дорогих учителей. Берегите каждое воспоминание, которое подарила школа!

**Диана ХРИПКОВА,**

**выпускница 2007 года.**

# Без – сезнекеләр, Туфан ага!



12 нче кызлар гимназиясенә эшкә килгәнче, Туфан абыйны чыгышларын радио-телевидениедән тыңлап, әсәрләрен укып, спектакльләрен карап кына беләидем. Мин Туфан Миңнуллинның иҗатына гашыйк идем. Әсәрләрендә күтәрелгән проблемалар, андагы фикер тирәнлеге, язу осталыгы мине әсир иткән иде. Ул усал кеше булырга тиеш кебек иде.

Кызлар гимназиясенә эшкә килгәч (Тукай урамындагы иске бинага), Туфан аганың монда еш килүен күрдем. Татар кызларының яхшы бинада укырга хаклары бар, дип заманча яңа бина салдыру артыннан күпме тырышканын директорыбыз белә дә, үзе генә белгәндер. Вәгъдәсендә тора торган кеше икәнлеген тагын бер раслады ул.

Туфан абый дигәндә, калын күзлек пыялалары астыннан җитди таләпчән карашлы, гөрелдәвек тавышлы халык депутатын күз алдыма китерәм. Әйе, халык депутатын! Һәр адымын, һәр мизгелен без дип, татар дип тырышкан кешене. Туфан абыйның изгелекләрен (ә бәлки ул аны изгелек дип тә түгелдер, сайлап куйган халкы алдында бурычын үтәүдер) берничә сүз белән генә әйтеп бетереп булмый.

Олыны олы итә белгән, кечесенең күңеленә юл тапкан Туфан абый. Сагынабыз сине, юксынабыз. "Кызыл тышлы дәфтәр"дән күңелебездәге сорауларга җавап табабыз, пьесаларыңдагы геройларың белән бәхәскә керәбез, алдан күрүчәнлегеңә сокланабыз, арабызда булмавыңа уфтанабыз.

Татар кызларының яхшы бинада укырга хокукы бар дип, үзең йөреп салдырган бинаның ачылу көннәре. Президентыбыз дәресләргә керәсе. "Менә, сеңлем, алып куй. Миннән бүләк булыр бу", - дип, сөекле шагыйребез Тукайга багышланган сайланма әсәрләрне дәрес алдыннан кабинетка кертеп тапшырган идең. Затлы тышлы, рәсемнәр, фотолар белән тулыландырылган Тукай җыентыгы да Туфан абый идеясе белән чыгарылган икән. Дәресләрдә "Туфан абый бүләге", дип кулга алабыз.

Тагын бер вакыйга искә төшә. Нindидер кичәгә әзерләнәбез. Бер укучыга Тукайның мәктәп дәреслегенә кертелмәгән шактый авыр шигыре ятларга бирелде. Бала шигырьне өйрәнде, ләкин бер җирендә урынын алыштырып өйрәнгән. Тырышып-тырышып та истә калдыра алмагач, кем аның буталганын сизәр икән дип кул селкедем. Син сиздең аны, Туфан абый. "Сеңлем, менә болай ул", - дип сөйләп тә күрсәттең. Кызларыбызның татарча сөйләшкәннәренә ничек куана идең. Вьетнам кызы Буй Тхи белән рус кызы Афиногенованың саф татар телендә кичә алып баруларын зур канәгатьләнү белән карап утыра идең. Син бүләк иткән көмеш беләзекләр укучы кызларыбызга нинди истәлек булып калдылар!

Театрда "Туфан абый, бергә фотога төшик әле", - дигәч, тирә-ягыңдагы кешеләргә карап: "Болар минекеләр, 12 нче гимназиянекеләр", - дигән идең. Әйе, Туфан ага, без – сезнекеләр! Бу безгә зур җаваплылык өсти.

"Йолдыз кабына, яши, тирә-якка нур чәчә. Аннан сүнә, ә нурлары әле бик озак галәм буенча оча, яктырта. Шундый йолдыз кебек иде Туфан Миңнуллин", дип язды газета укучы Р.Сәхәбетдинов. Без Синнән үрнәк алып яшәргә тырышырбыз, Туфан ага.

**Рузилә Тәлгат кызы ХУҖИНА,**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы.**



# Һәр көнебез – бәйрәм!



Мин 12 нче кызлар гимназиясе белән беренче тапкыр танышкан вакытта ул Тукай урамындагы кечкенә генә бинада урнашкан иде әле. Бинасы кечкенә генә булса да, ничектер күңелгә якын, җылы тоелды ул безгә. Әтием белән әниемә дә андагы укытучылар да, укучы кызлар да ошады. Бертавыштан мин дә шунда укыячакмын дигән карарга килдем.

Беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап керәчәк 1 нче сентябрь көнен бик дулкынланып көтеп алдым. Шулай булмыйча ни, бергә укыячак кызлар белән дә таныш түгел, укытучы апаны да бер генә тапкыр күргән... Җитмәсә, гимназиянең яңа бинасы ачылу тантанасына бик күп дәрәҗәле кунаклар да киләчәк икән...

Яңа формамны киеп, кулыма беренче укытучыма дигән чәчәк бәйләмен тотып, әти белән әнине дә ияртеп гимназиягә килдем. Ә андагы кеше... Бергә укыячак кызлар да, гимназия дә бик ошады. Ошамаслык та түгел: бик зәвык белән төзелгән, матур бина иде ул. Килгән кунаклар да берсеннән-берсе затлы. Республикабыз Президенты Рөстәм Миңнеханов та, Казан мэры Илсур Метшин да бар иде. Шундый олы кунакларның без нәниләрне зурлап котлаулары ни тора! Шушы гимназия бинасын төзетү өчен җан атып йөргән депутат Туфан абыйның сүзләре бигрәк тә күңелемә якын булды. “12 нче кызлар гимназиясенә Әлмәндәрнең ун гомерен телим”, - дигән иде ул... Беренче дәрес тә, аннан соңгы концерт та истә калырлык булды. Укытучылар да бер дә усал булып чыкмады. Менә инде өченче ел бик теләп укыйбыз. Мондый якты, җылы, матур бинада үткән һәр уку көне бәйрәм кебек тоела безгә. Ун Әлмәндәр гомередәй озын булсын гомерең, яраткан гимназиям!

**Диләрә ГАНИЕВА,**
**3 нче “А” сыйныфы укучысы.**






Если мы чего-то не понимаем, мама не скажет, что мы вообще глупые по своей сути, мама объяснит, что мы обязательно поймём и сумеем, а сама научит и покажет, как. Еще раз и еще. В камерной обстановке гимназии сложно не чувствовать, что ты вписана в число детей классного руководителя, учителя любимого предмета, учителя предмета, который ты не понимаешь, учителя продлёнки, учителя начальной школы. А сколько детей у директора гимназии, Ильхамии Абдулхаевны… От каждого учителя я брала столько, сколько он давал нам от сердца каждый день нашей учёбы в этих стенах. Я шла по университету и знала, что когда я буду анализировать текст, чью-то речь или столкнусь с нравственной дилеммой, за моим плечом будет стоять Валентина Алексеевна. Я шла домой после учёбы и думала, что бы сказала Полина Евгеньевна напоследок только что отведённого мной урока английского. Встречая что-то незнакомое, будь то понятие, поведение или сложная для оценки ситуация, я старалась отстраниться, забыть всё, что знала до этого, и попытаться, как учила нас Сазида Исмагиловна, сформулировать всё с самого начала, явление это, признак или свойство. В книгах, фильмах и героях читаю между строк и нахожу параллели и метафоры, как землянику под кустом, вместе с Альфиёй Чулпановной. А когда в коридорах гимназии меня заключает в тёплые объятия Флёра Абдулловна, я всегда немножко первоклашка, неважно, 7 ли мне, 17 или 27. Невероятно лестно быть вписанной в их духовные материнские паспорта: жить становится осмысленнее, многослойнее.



Мне наивно кажется, что живя с убеждением, что у тебя есть для кого быть сильнее, умнее и добрее, что где-то есть тот, кого ты будешь защищать и оберегать, неважно, родной он тебе или нет, ты растёшь сам, рационально и духовно, отдаёшь другому, а внутри остаётся больше, чем прежде. Было бы хорошо относиться как такой вот духовный родитель к каждому, кто встречается тебе по жизни и идёт рядом какой-то её промежуток.

Для себя я модифицировала неофициальный девиз гимназии «вы же будущие матери» и обобщила материнскую философию в родительскую, так как склонна верить в равную степень ответственности родителей за ребёнка. Когда у ребёнка спрашивают, кого он больше любит, он разрывается между обоими родителями. И правильно делает. Возьмём ребёнка постарше и с более широким кругом общения. Если считать родителей за одно целое, то сложно сказать, кто на протяжении этих десяти лет обучения оказывает больше влияния на ребёнка: родитель или школа. Возможно, сама став опытным родителем, я поменяю своё мнение, однако, сейчас я на стороне взаимовыгодного сотрудничества школы и семьи. Нельзя привести ребенка в школу и забыть про него, уповая на однажды сделанный выбор учебного заведения и на компетентность и ответственность учителей. Нельзя пассивно наблюдать за поведением ребёнка в классе, учитывая лишь его успеваемость и посещение, а все его душевные метания и подростковые проблемы предоставить решать семье.

Наверняка, я рассуждаю так, потому что мои родители все мои 27 лет были для меня и родителями, и учителями. На мне так же, как на девичьей гимназии, очень много навешанных ярлыков, один из моих личных - «учительская дочка». Для меня же как для ребёнка было личной ответственностью учиться хорошо. Когда мама пришла в мою гимназию учителем алгебры и геометрии в моём 8-м классе, ответственность стала огромной. Я не могла заставить маму краснеть или каким-то образом оправдываться за меня и мои дурости. На четыре года мама совместила в себе и строгого учителя, и не менее строгого родителя. Я до сих пор не в силах осознать, чего это стоит - быть объективной по отношению к собственному ребёнку. Однако, я до сих пор не знаю женщины справедливее, рациональнее и душевнее. Да, всё это вместе. Если вы сочтёте меня необъективной, потому что я дочь, приглядитесь, пожалуйста, я ещё и ученица. Когда я раскладываю ситуацию по полочкам и спрашиваю, на какой результат было нацелено то или иное действие, я знаю, это Рузиля Гарифулловна во мне разлагает сумму на составные части. Когда я метафорами пытаюсь объяснить себе или другому человеку какую-то жизненную закономерность, я знаю, это мы с мамой пытаемся вдохнуть поэзию в сухие цифры статистики (или прогрессии).

Маму и Рузилю Гарифулловну порой разделить невозможно. Невольно задумаешься, а стоит ли. Мама может стать учителем. Учебное заведение может стать семьей. Давайте не будем возводить во главу угла неизвестно кем установленные границы. Не делите людей на умных и глупых, плохих и хороших, мальчиков и девочек, умножайте людей на себя. И да будет ваше произведение прекрасным.

**Ильянур АЛМАУТОВА,**
**первая выпускница гимназии.**



# ТУФАН ЯГЫ

...“Мәскәүләрдә, Парижларда танылып та үз авылындагы кешеләр якын итмәгән язучыны мин зур язучыга санамыйм!”- дип сөйли иде Туфан Миңнуллин. Мин уйга калдым... Ничек инде ул шундый бөек шәһәрләрдә танылып та язучы дип саналмасын ди? Саналмый икән шул! Әгәр дә үз авылыңдагы иң якын кешеләрнең синңа мәхәббәте, соклануы һәм горурлануы булмый икән, ул язучы була алмый. Бу бөек исемне иң башта авылдашларың акласын, ә аннары син үзең дә аны тоярсың. Туфан абый язучы дигән исемне горур йөрткән, чөнки ул һәрчак иң беренче чиратка туган ягын, туган телен куйган. Туфан абый Миңнуллинның туган төбәгенә кайту бу сүзләребезне кабат дәлилләде.

Әйе, бу безнең өчен зур бәйрәм булды. Автобуска әле утырмадык, ә күңел нindидер могҗиза көтә иде. Килеп җитү белән, безне бик мөлаем абый-апалар яратып, үз итеп каршы алдылар. Алар арасында Туфан абыйның якташлары һәм балачак дуслары да бар иде. Без аларның Туфан абый белән үткәргән көннәрен, елларын бик җентекләп, тәмләп сөйләгәннәрен тыңлый-тыңлый аның Мәрәтхуҗадагы йорты янына якынлаштык. Алар һәрберсе дә Туфан Миңнуллин турында үзенчә йомшак итеп, кызыклы итеп һәм бик сагынып сөйләделәр. Апалар берсеннән-берсе уздырып бөек язучыбыз турында хатирәләр яңарттылар. Без аларны тыңлап туя алмадык. Әйе, ул үз авылында чыннан да бөек һәм һәр вакытта да дөреслек өчен көрәшә торган шәхес итеп истә калган. Без моны сүзләреннән генә түгел, гамәлләреннән дә күрдек...

Туфан абый төзеткән Олы Салтык авылындагы мәктәпкә дә кермичә китә алмадык. Анда берсеннән-берсе матур, акыллы кызлар һәм егетләр татар телендә белем алалар. Гүзәл бинаның бер почмагын тарихи музей алып тора. Бу музейны авылда яшәүче халык үзләреннән дә өлеш чыгарып, тулылындырып тора икән. Мәктәптә белем алучы балаларга, белем бирүче укытучыларга иң кадерле булган музейның бер почмагын Туфан абыйның китаплары, язмалары алып тора. Бу мәһабәт белем йорты, күңелебезгә бик якын булып калды.

...Без кайтырга чыктык. Шатлыклы һәм моңсу, соклану һәм сагыну хисләре бергә кушылдылар... Күңелем тулды... Кайтканда күзем Ләбәч тауларына төште. Барганда мин аларга алай игътибар да итмәгән идем, ә хәзер бөтенләй икенче, ничектер якын булып тоелдылар. Эх, шушы гүзәл Кама Тамагы якларына кайтуыбыз мәңгегә истә калсын иде.

“Яшәр өчен бетмәс көч алырга,
Олысына һәм кечегә.
Мәхәббәтле, ямьле, мәрхәмәтле
Туган ягы кирәк кешегә!”- дип яза Фәнис Яруллин. Туфан абый Миңнуллин да туган ягына яшәргә көч алырга, ирешкән максатларын авылдашларына, якыннарына ишеттерер өчен канатланып кайта торган булгандыр. Әйе, яңа үрләр яуларга канат биреп, безне гел илһамландырып торган туган ягыбыз бер генә шул. Туфан абый моны гомере буена тоеп яшәгән!

**Ландыш СИРАҖЕТДИНОВА,**
**8 нче сыйныф укучысы.**
**Казан - Кама Тамагы –**
**Олы Мәрәтхуҗа – Олы Салтык.**



***Мәктәп елларының кабатланмас хатирәләре, кочак-кочак сагыну һәм рәхмәт хатлары... Татарчамы, русчамы — барыбер, иң мөһиме чын күңелдән бөреләнеп чыккан керсез, саф хисләр... Бүген гимназиябезнең хәтер йомгагын аның горурлыгы — укучылары сүтәчәк. Сүз — сезгә, кадерле укучылар!***

***Редакция.***

# Балачакка кире кайтып булмый...

Хәзер дә исемдә беренче тапкыр мәктәпкә килүем. Кара капкалар, кызыл кирпичтән ясалган 3 катлы бина, зур ишеге һәм эчендәге кечкенә класслары...

Мине икенче катка әнием алып барды. Ул миңа: “Кызым, син кайсы класска керәсең килә? “А” классынамы яки “Б” классынамы?”, – дип сорады. Мин белмәдем, әлбәттә, минем өчен бу сәер сорау иде. Ләкин бер мизгелдә барысы да үзгәрде. Икенче каттагы иң беренче бүлмәгә аяк атладым. Анда матур, чибәр, озын чәчле, күзлек кигән хатын-кыз утыра иде – Альмира Миңнуровна. Ул миңа карады да, елмайды, шуннан соң мин ап-ачык үземне шушы укытучы белән, шушы “Б” классында гына күрдем. Аның елмаюы, ихлас күңеле миндә нидидер ышаныч уятты. Безнең класста 8 кыз укыды, аның дүртесе Алсу иде. Без бөтенебез дә дус, тату класска әйләндек. Дөрес әйтәләр: беренче укытучы иң якын була, аңардан күп нәрсә тора. Кая гына барып, кемнәр генә булсак та, без әтиәниебез, туган ягыбыз, туган мәктәбебездә беренче укытучыбыз үстергән бала булып калачакбыз. Шуңа күрә беренче укытучым, Альмира Миннуровнага мең-мең рәхмәт әйтәсем килә. Укытучы апам сабый күңелемә ачкыч таба белде, сабыр булды, күп нәрсәгә өйрәтте.



“Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел, инглизчә дә яхшы бел”, – дигән девиз белән яшәде безнең мәктәп. Татар мәктәбенә карамастан, башка телләр дә монда тиешле дәрәҗәдә бирелделәр. Инглиз теле укытучысы Полина Евгеньевна белән рус теле һәм әдәбияты укытучысы Валентина Алексеевна минем йөрәгемдә аерым урын алып торалар. Алар кырыс булсалар да, безгә бик күп белем бирделәр. Рус теле кагыйдәләре һаман да минем хәтеремдә сакланалар.

Безнең мәктәбебез әллә ни зур булмады. Концерт залы, физкультура залы, бию залы, барысы да бер зал иде. Ләкин бу безгә мәшәкать тудырмады. Безнең физкультура укытучыбыз Зөфәр Абделхәевич дәресләрен бик оста оештырды, аның һәрбер дәресе бик кызыклы, мавыктыргыч үтте. Хәзер дә безнең гимназия кызларыннан яхшырак скакалкада сикерүчеләр булмас дип уйлыйм.

Рахман Фәйзрахманович... Безнең завучыбыз, безнең укытучыбыз. Ул безне үстерде, безгә үгет-нәсихәт бирде. Күп вакытын безгә багышлады. Нәрсә яхшы, нәрсә начар икәнен жентекләп аңлата иде. Без аны сагынабыз, ул һәрберебезнең йөрәк түрендә һәрчак яшәячәк. Обсерваториядә ял итүләр, күңелле һәм кызыклы вакыт үткәрүләр онытылмаслык мизгелләр булып сакланалар. Аның авыр туфрагы җиңел булсын, минем истәлегем аңа дога булып ирешсен.

***(Дәвамы 7 нче биттә.)***



В силу общей интеллигентности и субтильности мы агрессору лёгких телесных повреждений и тяжких моральных травм, конечно, не нанесём, но прожигать взглядом, не говоря ни слова, да так, что душа бьётся об стенки желудка, - это ведь так по-женски, правда?

Я не стремлюсь вложить людям в головы своё видение гимназии как образовательного и воспитательного учреждения, не могу порой отключить чужие сочувствующие взгляды, как и не вижу смысла кричать на каждом углу "наша школа - лучшая школа в мире, вы ничего не понимаете", ведь тогда меня точно поставят на ту самую полку с подозрительными личностями и вряд ли когда-нибудь позовут в гости или познакомят со своими детьми.

У окружающих может сложиться мнение, что из нас растят армию женщин, эдаких современных амазонок. Парадокс состоит в том, что амазонистость не зависит от того, какую именно школу ты окончишь. Более того, я вижу, что девочки, отучившиеся С мальчиками, относятся к ним гораздо высокомернее, чем большинство девочек-выпускниц школ БЕЗ мальчиков. Школьный курс анатомии и физиологии человека говорит, что мальчики в период полового созревания поначалу немного отстают от девочек в учебе, росте и развитии. Мальчиков сотрясают гормональные бури, их нещадно штормит, учёба не в приоритете, а девочки, чувствуя своё временное превосходство, укрепляются в мнении, что "эти мужчины ничего не понимают". Некоторые девочки проносят с собой это сомнительное знание сквозь всю жизнь и целыми поколениями передают дальше в вечность эстафету презрения мужчин. Зашоренное сознание выуживает подтверждение правомочности этой позиции в любой жизненной зарисовке, где гендерное различие возводится в ранг главного отличия людей друг от друга. Иными словами, "мужчины с Марса, женщины с Венеры". Словами вышеупомянутых женщин, "да что с этих мужчин взять".

Картина мира женщин, думающих таким образом, выглядит неутешительно: они обречены связывать свою жизнь с мужчинами, кого изначально считают глупее, слабее, ограниченнее, безнадежнее. За все 10 лет обучения в женской гимназии ни от одной женщины-преподавателя или воспитателя я не слышала ни намёка на ущербность мужчин и превосходство женщин. Ни разу я не почувствовала ни дуновения в сторону "я всё смогу сама и даже лучше мужчины". Не видела промашек мужчин во время их пубертата, не видела их подростковой агрессии, не слышала ругани, взаимных унижений, не видела кровавых драк. Естественно, в обстановке, где я была избавлена от необходимости выстраивать межполовые отношения, одновременно следя за тем, чтобы меня не обидели и не задели, легче было и учиться, и вкладываться в свое развитие: заниматься тем, чем хочется, участвовать во всех мыслимых и немыслимых конкурсах и олимпиадах. Я не знала, что мужчины хуже или ограниченнее. Меня этому не учили. Более того, я до сих пор пребываю в счастливом неведении. Моему сознанию нечего искать в мужских ошибках, каких-то сокровенных причин, которые можно объяснить в первую очередь иным набором хромосом. Когда я вижу, как ошибается мужчина, я думаю, ну подумаешь, ошибся, все мы люди. Упал, отряхнулся, пошёл дальше. Будто сама никогда со своих каблуков не падала.

С тех пор, как мы с моими девочками выпустились из гимназии, прошло всего лишь десять лет, и за эти годы мне сложно сформулировать, почему именно эта гимназия, почему не классическая школа. Признаюсь, я не могу составить чёткий список на предмет наших отличий от остальных девочек.

Мысленно отмахиваясь от перспектив ответственного материнства в детстве и в старших классах, я по-новому взглянула на эту фразу, поступив в университет. С изумлением я прислушивалась к внутренним движениям и перестановкам и после окончания университета. В какой-то момент я осознала, что в действительности, какими бы амбициями и тщеславными целями я ни обладала, моя задача как женщины - стать матерью. Природу не проведёшь навязанными обществом песнями о женской эмансипации.

**Из того, что я вынесла из школьных лет, я отчётливо помню, что в нас вкладывали сознание ответственности, твердили "вы будущие матери". В этом с остальными девочками у нас отличий мало: всем такое говорили в детстве, когда ты за одну ногу висишь на дереве или вот уже почти догнала сестру за какой-то детской безумной целью. Просто "вы же будущие матери" не осталась в детстве, а периодически внедрялась нам в сознание во время учёбы в гимназии, мы прожили с этим маяком дольше.**

Я убеждена, что дело даже не в техническом вопросе, как выносить, родить ребёнка и вписать себя в свидетельство о его рождении. Мне хочется думать шире: с того самого момента, как мы прикрепились к матери в виде набора клеток, мы неразрывно связаны на всю жизнь. Родившись и взрослея, мы слушаем слова матери, мы на неё похожи, к ней мы бежим за утешением, за советом, с ней мы первой делимся радостью. Если мы ошибаемся, мама не считает нас неудачником, не торопится в нас разочароваться раз и навсегда и даже не помыслит о том, чтобы перестать нас любить.

***(Продолжение на 12 стр.)***





В разговоре с еле знакомыми людьми, будь то собеседование или ни к чему не обязывающий обмен незапоминающимися репликами в случайной компании, зажмуриваюсь каждый раз, когда речь заходит о школе.

- А ты из какой школы?

- Из 12-ой гимназии

- А, это та, которая еврейская?

- Нет.

- Та, которая на Островского?

- Нет, это 11-ая, а рядом - 12-ая вечерняя, только я всё равно не оттуда.

- Откуда тогда?

- Из гимназии для девочек на Тукая.

Дальше всё, как по нотам: вот мы только что вели великосветский разговор о высоком, а вот меня на вытянутых руках относят на полку с людьми диковинного, непредсказуемого, а значит, подозрительного содержания. Осторожно, полка закрывается прозрачными дверьми, при выходе будьте осторожны: под ногами - тонкий лёд. Меня спрашивают сквозь стекло (а вдруг что учудит), а не та ли это гимназия, которая татарско-турецкая. Физически чувствую, как мои зрачки сузились, и пытаюсь усилием мысли расширить их обратно. Думаю, никуда не денешься, ТТЛ и мы - как две девочки в одинаковых платьях на школьной вечеринке: "Ой, какая забавная ситуация, шарман-шарман", а убирая воображаемую соринку с плеча нечаянного двойника, каждая хочет верить, что "платье и впрямь отличное, но мне идёт больше".

Вслух я говорю "Что вы, что вы, татарско-турецкий лицей - это интернат, а мы ведь только грызём гранит без мальчиков, а так у нас фойе кишмя кишит ВООБЩЕ-ТО". Надрыва в голосе собеседник может и не уловить (я же через стекло с полки, помните?). Взгляд теплеет, он приоткрывает дверцы, достаёт меня маленькую, сажает на ладонь себе большому и мудрому и ласково начинает расспрашивать: "Ну и как вам училось без мальчиков? Скукота, небось". Я трогаю ножкой тонкий лёд, на который меня выпустили, и начинаю легкую Пропаганду Раздельного Обучения (стандартный набор): отсутствие раздражающих факторов, вроде хрестоматийного дергания за косички и перманентного аромата никотина в классе от стремительно мужающих одноклассников. Ещё нужно не забыть вздохнуть по возможности в любое время уйти в уголок подтянуть колготки, тяжкий крест наш, или поправить бретельку, периодически спадающее оружие наше.

В этих разговорах очень важно оставаться лёгкой и неглубоко копающей. Если копнёте глубоко и не там, случайно откопаете зарытый топор войны и сами не заметите, как верхушки деревьев начнут колыхаться от ваших с собеседником криков. Особенно противопоказано затрагивать серьёзные вопросы нужности и обоснованности гендерно-сегрегированного обучения тем, у кого не было возможности испытать его на себе. Отучившись от звонка до звонка десять тёплых лет в этой гимназии, я изо всех сил стараюсь держать под контролем русло беседы о ней. Это как разговоры о родственниках: чужие люди могут моих родных недолюбливать, могут ненавидеть, могут истекать желчью и ядом, потому что не пылают добрыми чувствами ко мне, с другими родными мы можем признаваться друг другу, что да, неидеальны, но упаси Бог людям со стороны высказать вслух своё яростное неодобрение.

***(Продолжение на 11 стр.)***



***(Дәвамы. Башы 6 нчы биттә.)***



Рузилә Гарифулловна мине 11нче класска хәтле озатты. Бу вакытта мин инде үскән кыз идем. Ул мине гел аңлады, миңа терәк булды, мине яклады. Аның яхшылыкларын мин хәзер генә аңлыйм. Класс эчендә ул безне орыша да иде, мактый да иде, төрле вакыты булды, ләкин укытучылар алдында гел яклады, безнең яхшы якларыбызны гына күрсәтте.

Безнең киңәшчебез һәм сердәшчебез Рузилә Тәлгатовна кебек укытучылар күбрәк булса, мин тагын да шатланыр идем. Ул безнең өчен янып яшәде, безне намуслы, кешеләргә карата шәфкатьле, мәрхәмәтле булырга өйрәтте. Аның акыллы киңәшләрен, үгет-нәсихәтләрен мин беркайчан да исемнән чыгармыйм.

Илһамия Абделхәевна – 12 нче номерлы татар кызлар гимназиясенең директоры, ә минем өчен ул беренче инглиз укытучым. Бәлки балалар өчен өч телне бер үк вакытта өйрәнү авырдыр, ләкин безнең гимназия кызларыбыз рәхәтләнеп ул телне үзләштерделәр. Безнең директорабыз безгә укытучылар кебек үк якын иде. Һәр җомга саен “линейкалар” да ул безне мактады да, орышты да, бездән чын кызлар, әдәпле, игелекле, акыллы кешеләр, булачак яхшы әниләр ясарга тырышты ул. Аның һәрбер сүзе минем колагымда бүген дә яңгырый. Илһамия ханым гел безнең мәктәбебез өчен көрәште. Кызлар гимназиясе Казанда булырга тиеш, мондый мәктәпне ябырга ярамый, аңарга яңа бина кирәк дип күпме теләк теләде, сорады... Хәзер гимназиябез яңа матур бинада үз тормышын дәвам итә. Илһамия Абделхәевна, Сез безне тырышып укырга, укытучыларыбызның, мәктәбебезнең данын төшермәскә, лаеклы кеше булып үсәргә өндәдегез. Рәхмәт Сезгә!

**Алсу САФИНА,**
**2006 нчы елгы чыгарылыш укучысы.**

# “ВАСИЛЬЕВАГА СӘЛАМ!”

Сыйныфташлар бик тату яши идек, бер-беребезгә кунакка йөрүләр дә шактый гадәткә кереп киткән иде. Шулай бер елны бик каты



авырып киткән идем, кызлар белән озак күрешмәдек. Ул вакытта Рахман Фәйзрахманович сыйныф җитәкчебез иде. Менә бер көнне дәрес беткәндә (мин авырып өйдә ятам бит инде), кызлар укытучыдан: "Кая барасыз, Рахман абый?" - дип сорагач, ул "Васильевага барам", - дигән. "Безнең Васильевага күп итеп сәлам!" - дигән кызларыбыз. Рахман абый елмаеп, мин санаторий “Васильево”га барам, безнең Васильевага түгел" дигән... Мин сәламәтләнеп килгәч, кызлар миңа бу мәзәк хәлне сөйләделәр. Бергәләп шаркылдап көлдек!

Рәхмәт сиңа, мәктәп еллары!

**Регина ВАСИЛЬЕВА,**
**2006 нчы елгы чыгарылыш укучысы.**

# ЙӨЗЕК КАШЫ

***Чумарина Флюра Абдулловна... Әйе, 12 нче кызлар гимназиясенең чишмә башы аның исеменә барып тоташа. 43 ел гомерен балалар укытуга багышлаган, шул вакыт эчендә йөзләгән укучыга хәреф танырга өйрәткән, кызлар гимназиясенең иң беренче 10 укучысын җитәкләп, Белем иленә алып кергән беренче Укытучы...***

2008 нче ел... Әлеге коллективта әллә ни күп эшләмәгәнлектән, күбесен бик белеп тә бетермим. Укытучы хезмәтенең шул ягы бар: янәшәңдә инне-иңгә куеп эшләгән кешеләрнең язмышы белән кызыксынырга, чын күңелдән бергә сөйләшеп утырырга һич кенә дә җай чыкмый, вакыт табылмый. Флюра Абдулловнаның исеме еш колакка керә, шуңа мин инде аның бу коллективта бөтенләй үз кеше, акыллы, кирәк чакта нәкъ менә син көткән җавапны, киңәшне бирүче икәнлеген йөрәгемнең иң нечкә кыллары аша сизеп алган идем.

Үзем дә эшкә соңга калып йөрергә яратмаганлыктан, мәктәпкә мин үземчә бик иртә киләм, ләкин миннән дә алда килеп утыручы кеше — ул Флюра Абдулловна. Әнә ул, гадәттән тыш эшлекле кыяфәт чыгарып, йә уздырылачак дәресенә әзерләнә, йә дәфтәр тикшерә, шул арада килгән укучыларын барлый, ата-аналары белән дә сөйләшеп алырга җай таба. Менә шулай мәктәп дөньясында бөтерелеп, алда булган авырлыкларны җиңә-җиңә 40 ел гомер узып та киткән. "Укытучы хезмәтен сайлаганлыгызга үкенмисезме?" - дигән сорау бирәм. Ә ул бер дә рияланмый гына, үзенчә үтемле һәм тапкыр итеп: "Үкенмим, өлешемә тигән көмешем", - дип җавап бирә.

Флюра Абдулловнаны бу гимназиягә нигез салучыларның берсе дисәк тә һич ялгыш булмас. Ул монда гимназия ачылганнан бирле. Үткән елларны исенә төшереп менә нәрсәләр сөйләп алды ул миңа: "1993 нче елның август ае. Мине Ф.А. Илдарханова Мәгариф министр-лыгына чакыртып алды. "Без Казанның Вахитов районында кызлар гимназиясе ачарга булдык. Сезгә шунда укытучы булырга тәкъдим итәбез", - диде. Бу бик кызыклы иде. Чөнки республиканың бер генә шәһәрендә дә мондый кызлар гимназиясе юк. Булачак директорым белән таныштырдылар. Ул элек райкомда эшләп килгән кеше, әлбәттә, мәктәп эше аның өчен ят иде. Барлык оештыру эшләрен үз өстемә алырга туры килде. Радио-телевидение аша ата-аналарга мөрәҗәгать итү, таныш-белешләр арасында аңлату эшләре алып бару нәтиҗәсендә беренче елны 10 татар кызын үз гимназиябезгә җәлеп итә алдык. Безгә Тукай урамында урнашкан балалар бакчасы бинасын бирделәр. Шундый күңелле булды бу укучы кызлар белән эшләве!" - дип, күк йөзедәй зәңгәр күзләрен



балкытып алды ул. Бу елларның хатирәсе гомерен балалар тәрбияләүгә биргән укытучы өчен бик тә кадерле иде бу минутларда. Гомумән, Флюра апа сөйләгәнне тыңлыйсы гына килеп тора. Беркайчан да зарланмас, кешене түбәнсетмәс, аның кимчелекле якларын күреп астыртын көлмәс. Кайгы-хәсрәтеңне һәрчак уртаклашырга әзер булган мондый Остаз янында беркемгә дә уңайсыз түгелдер дип уйлыйм. Ул укыткан укучылар белемле, акыллы, тәртипле һәм тәрбияле. Шуңа күрә дә нәни укучы кызлары аңа "Без Сезне яратабыз", "Сез иң матур укытучы" дигән сүзләрне бик еш әйтәләр. Тәүге мәртәбә гимназия бусагасын атлап кергән кызларыбызның әти-әниләре балаларын Флюра Абдулловна кебек тәҗрибәле укытучы укытканга шатланып туя алмый. Ә без, гимназия укытучылары, Сезнең безнең арабызда булуыгызга, көч-дәрт өстәп торуыгызга чиксез шатланабыз. Күңел түрегез һәрчак шулай киң булсын, бозлы яңгырлар яшәү дәртен сүндермәсен, хөрмәтле затлы Остазыбыз!

**Гөлнур Зәкәрия кызы**
**НАСЫЙБУЛЛИНА.**

**Рәсемдә: Флюра Абдулловна укучылары янәшәсендә. 2001 нче ел.**



Когда я в первый раз попала в гимназию, помню, я очень приятно была удивлена. Повсюду ковры, тишина, вкусные запахи, и так по-домашнему уютно, даже в коридорах! Атмосфера, которая там царила, очаровала меня! И мы, приняли решение, что перевести меня сюда, несмотря на то, что в те времена, дорога занимала почти час, лучшее решение. О чем я не пожалела, и не жалею до сих пор. Быть выпускницей этого заведения, не только большое счастье, но и огромный опыт, который помогает до сих пор, уже будучи за ее пределами.

У меня были большие проблемы с английским языком, ведь девочки в гимназии изучали его уже в начальных классах. Я же начала изучать его с нуля в 5 классе. И естественно, что мне требовалась помощь. Меня оставляла после уроков не кто-нибудь, а сама директор - Ильхамия Абдулхаевна. Помню, как дрожали коленки, когда шла в кабинет директора для индивидуальных занятий. Я очень благодарна ей! Ведь это время потраченное на нас, ей никем не оплачивалось, и делалось это все от чистого сердца. Такого больше не встретишь нигде. Весь педагогический состав переживает за каждую ученицу и старается передать ей максимум знаний и умений. Если того требует ситуация, тебя никто не прогонит, всегда можно было поделиться со своими проблемами, зная, что тебя выслушают, поймут и поддержат. Так продолжается и по сей день, даже окончив гимназию, тебя никто не забыл. Каждый учитель помнит всех учениц, это особенно приятно.

Я счастлива, что окончила именно эту гимназию, ведь тогда и теперь она была и остается второй семьей, где тебе всегда рады, всегда интересуются твоими родными, успехами, проблемами, готовы поддержать во всем! Это счастье, быть частью такой большой семьи!

**Юлия АЛЕКСАНДРОВА,**
**выпускница 2006 года.**

Беренче сентябрь, 1996 нчы ел. Әле дә исемдә ул көяшле, якты җылы көн. Иртән-иртүк чәчләргә ап-ак бантиклар куеп, чәчәк тотып мәктәпкә киттек. Каушау, сөенү, курку - барысы да бергә кушылган иде. Безнең өчен олы бәйрәм, яңа юлга аяк басу...

Әти-әниләр безне кулдан-кулга укытучыларыбызга тапшырдылар, ә алар безне җитәкләп яңа уку иленә алып кереп киттеләр. Безгә беренче белемне биреп, тормышка беренче адымнар ясарга булыштылар.

Гимназия безнең өчен икенче өй булды. Истә калырлык якты вакыйгалар бик күп иде. Беренче укытучыбыз Флюра Абдулловна, өлкән сыйныфта безнең җитәкчебез - Рузилә Гарифулловна безне үз балалары кебек тәрбияләп үстерделәр. Укытучыларыбыз гел безне кайгыртып, тәрбияләп, яратып укытты. Үзләренең бар җанын, бар мәхәббәтен безгә - укучыларына бирделәр. Күпме көч түгелгәндер безгә белем һәм тәрбия бирер өчен! Гимназиябез бездә туган ягыбызга, туган телебезгә мәхәббәт уятты, чит телләрне өйрәнүдә этәргеч булды, гомумән, барлык өлкәдә дә нигезле белем бирде, безне кеше буларак та формалаштырды. Ун ел буена безнең белән бергә үсеп, барлык сөенечне дә, кайгыны да уртаклашып, безнең дустыбыз, таянычыбыз, безнең зур тату гаилә булды ул.

Гимназияне тәмамлауга инде 7 ел үтте, ә без аңа әле дә рәхмәтле. Гимназиядә укыган еллар күңелдә якты бер урын алып тора, без аны гел җылы хисләр белән генә искә алабыз.

Яраткан гимназиябез, яңа казанышларга ирешеп, акыллы укучылар, кызлар тәрбияләп әле озын-озак еллар безне сөендереп яшә!

**Гүзәл ДӘҮЛӘТБАЕВА,**
**2006 нчы елгы чыгарылыш укучысы.**